ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Кутузова ул., дом1,
город Лениногорск, 423250

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

Кутузов урамы, 1нче йорт,
Лениногорск шәһәре, 423250

Тел.: 5-13-80. leninogorsk.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 август 2019 ел Лениногорск № 207

Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышу нәтиҗәләрен карап, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. ТР, Лениногорск ш., Тукай урамындагы 16:51:010402:2340 номерлы җир участогына карата ике территоиаль зона Д-1 (эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция

билгеләнешендәге зона) һәм Р-1 (рекреацион-ландшафт территорияләре зонасы) зонасына Д-1 бердәм территориаль зонасын билгеләү;

1.2. ТР, ЛМР, Лениногорск ш., Мурзин ур., 69а адресы буенча урнашкан № 16:51:010701:0158 җир участогына карата, әлеге участокны торак йорт өчен фактта файдалануга туры китерү максатыннан, территориаль Д-3 зонасының бер өлешен (мәгариф һәм фәнни комплекслар урнаштыру зонасы) Ж-1территориаль зонасына (торак йортлар төзү зонасы) үзгәртү ;

1.3. ТР, Лениногорск шәһәре Агадуллин урамы, 2нче йорт, 1нче корпус адресы буенча урнашкан № 16:51:012401:1961 җир участогына карата, укыту корпусын күпкатлы йорт итеп реконструкция ясау максатында, Д-3 территориаль зонасының бер өлешен (мәгариф һәм фәнни комплекслар урнаштыру зонасы) Ж-2 территориаль зонасына (күпкатлы һәм урта катлы йортлар төзү зонасы);

1.4. ТР, Лениногорск, Высоковольтная урамы, 19 а адресы буенча урнашкан 16:51:010704:194 кадастр номерлы җир участогына карата Д-3 территориаль зонасының бер өлешен (мәгариф һәм фәнни комплекслар объектларын урнаштыру зонасы), җиһазлар производствосын урнаштыру проектын исәпкә алып, ПК-3 территориаль зонасына (IV-V класс куркынычлык объектлары зонасы) үзгәртү.

1.5. ТР, Лениногорск ш., Агадуллин ур., 6 йорт адресы буенча урнашкан № 16:51:012401:1956 җир участогы һәм ТР, Лениногорск ш., Агадуллин ур., 4 йорт адресы буенча урнашкан № 16:51:012401:1958 җир участогын, кунакханә һәм җәмәгать туклануы предприятиесе буларак куллану максатында, Д-3 территориаль зонасының бер өлешен өлешен Д-1 (мәгариф һәм фәнни комплекслар урнаштыру зонасы) территориаль зонасына үзгәртү.

2. Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә һәм яңартылган документларны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның федераль геомәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://Leninogorsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Карар үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. Н. Карасевка йөкләргә.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов